# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Конституциясенең 108 статьясына үзгәреш кертү турында**

1 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең 108 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №9-10; 1994, №11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, №2-3, №12; 1996, №11; 1999, №6, №8 (1өлеш); 2000, №6) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президенты итеп Татарстан Республикасының утыз яшьтән яшьрәк булмаган, сайлау хокукына ия булган һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләрен белүче гражданы сайланырга мөмкин.».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 19 декабре
№ 494